**ГЛАВА**
**КУГАРЧИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422662, с. Кугарчино,**
**ул. Советская, дом 65а**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**КҮГӘРЧЕН АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**422662, Күгәрчен авылы,**
**Совет урамы, 65а йорт**

Тел.: (84361) 28-589, факс: (84361) 28-589, эл.адрес: Kugar.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 18.11.2022 года с. Кугарчино № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Күгәрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 30 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 30 ноябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 30 ноябрендә15 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче төркем инвалидларыннан , бөтенләй ялгыз яшәүче 80 яшькә җиткән пенсионерлардан һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала т , аларнын саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан артып китә алмый, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- авыл чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- су белән тәэмин итү системаларын, су кудыру башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистарту һәм су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;
- Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Күгәрчен һәм Зәңгәр-Күл авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш китертү өчен транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Күгәрчен һәм Зәнгәр-Күл авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);

ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Зәит урамы, 1 А йорт; адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Сафин